| Республика Татарстан | | Татарстан Республикасы |
|---|---|---|
| Исполнительный комитет Менделеевского муниципального района | | Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.03.2025 Менделеевск ш. № 191

2025 елга эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза уздыру планын раслау турында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 30 июлендәге 472 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы муниципаль норматив актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының муниципаль хокукый актларына экспертиза уздыру планын кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад, алгарышлы социаль икътисадый үсеш территориясен һәм эшкуарлыкны үстерү буенча урынбасары Л.Р.Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Искәндәров

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2025 елның 10 мартындагы
191 номерлы карарына  кушымта

2025 елга эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының муниципаль хокукый актларына экспертиза уздыру планы

| № п/п | Норматив хокукый акт реквизитлары | | | План проектына норматив хокукый актны кертүне нигезләү | Фактtагы йогынтыны бәяләүне уздыру сроклары (башы-ахыры: ай, ел) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | Исеме. төре | Датасы, номеры | Эшләүче | | |
| 1. | «2024-2027 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкка, шулай ук шәхси эшкуар булмаган һәм «һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга ярдәм программасын раслау турында"Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карары | № 580 02.10.2023 | Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының алгарышлы социаль икътисадый үсеш территориясе бүлеге | Хокукый җайга салуны гамәлгә кертү йомгакларына анализ һәм аның нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү | 2025 елның 1 кварталы. |
| 2. | «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы ягыннан капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзү тәртибен һәм шартларын | № 197 28.03.2024 | Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының | Хокукый җайга салуны гамәлгә кертү йомгакларына | 2025 елның 2 кварталы. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | раслау хакында»Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карары | | алгарышлы социаль икътисадый үсеш территориясе бүлеге | анализ һәм аның нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү | |